**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча җәмәгать фикер алышулары башлану турында хәбәр итү**

20.07.2026 ел

Зеленодольск шәһәре Мэрының 2026 елның 17 июлендәге «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча җәмәгать фикер алышулары билгеләү турында» 02-03-05 номерлы карары нигезендә 20.07.2026 елдан 13.08.2026 елга кадәр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча җәмәгать фикер алышулары уздырыла.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча мәгълүмат материаллары исемлеге.

Җәмәгать фикер алышуларын уздыру тәртибе:

1) җәмәгать фикер алышулары башлануы турында хәбәр итү;

2) җәмәгать фикер алышулары каралырга тиешле проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм әлеге проектның экспозициясен яисә экспозицияләрен ачу;

3) җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект экспозициясен яисә экспозицияләрен үткәрү;

4) җәмәгать фикер алышулары беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;

5) җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Проект экспозициясе 27.07.2026 елдан 03.08.2027 елга кадәр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми http://zelenodolsk.tatarstan.ru сайтында «Территориаль планлаштыру документлары» бүлегендә һәм Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 46 нчы йорт адресы буенча Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәгенең мәгълүмат стендында ачылачак.

Экспозицияне уздыру вакыты-8 көн.

Җәмәгать фикер алышулары проекты экспозициясен карау режимы: Горький исемендәге мәдәният,сәнгать һәм халык иҗаты үзәге бинасында Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 46 нчы йорт буенча, дүшәмбедән җомгага кадәр 8.30 дан 16.30 га кадәр (эш көне булмаган, бәйрәм көннәреннән тыш).

Җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар 27.07.2026 елдан 03.08.2026 елга кадәр җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне түбәндәгечә кертергә хокуклы:

1) Зеленодольск муниципаль районы рәсми http://zelenodolsk.tatarstan.ru сайтының интернет-кабул итү бүлмәсе аша;

2) Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 46 нчы йорт, адресы буенча 207 нче

кабинетта җәмәгать фикер алышуларын оештыручыга язма рәвештә;

3) Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 46 нчы йорт адрес буенча, 207 нче кабинетта җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабына (журналына) язу юлы белән.

Җәмәгать тикшерүләрендә катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында белешмәләр (фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәү) урыны адресы - физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен) тапшыралар, әлеге белешмәләрне раслый торган документларны кушып. Күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган тиешле җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына һәм (яисә) биналарына хокук ияләре булган җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар шулай ук мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар турында, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр һәм мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, биналарга аларның хокукларын билгели яисә раслый торган башка документлар тапшыра.

Җәмәгать фикер алышуларын оештыручы тарафыннан тәкъдимнәр һәм искәрмәләр теркәлергә, шулай ук, җәмәгать фикер алышуларында катнашучының дөрес булмаган белешмәләр тапшыру фактлары ачыкланудан тыш, мәҗбүри каралырга тиеш.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәреш кертү проекты буенча консультацияләр түбәндә үткәреләчәк:

- 28.07.2026 елда 15.00 сәгатьтә Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 46нчы йорт адресы буенча Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге бинасының 1 нче кат фойесында.

Җәмәгать фикер алышуларын оештыручы:

«Зеленодольск муниципаль районының
архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ

Җитәкче П.Н. Сергеев